РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН ГЛАВА
НИЖНЕНАРАТБАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТҮБӘН НАРАТБАШ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«15» ноябрь 2021ел № 5

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә «Түбән Наратбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча гавами (ачык) тыңлаулар үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының 2021 елның 12 ноябрендәге 3-20 нгомерлы «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль берәмлекләре чикләрен үзгәртү турында» карары нигезендә, Түбән Наратбаш авыл җирлегендә яшәүчеләрнең гавами (ачык) тыңлаулар үткәрү юлы белән «Түбән Наратбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләре турындагы проект буенча фикер алышуда катнашу хокукларын үтәү максатларында


КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә «Түбән Наратбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча гавами (ачык) тыңлаулар үткәрүне Татарстан Республикасы, Буа районы, Түбән Наратбаш авылы, Совет ур., 2А йорт адресы буенча Түбән Наратбаш авыл җирлегенең Түбән Наратбаш авыл мәдәният йорты бинасында 2021 елның 10 декабренә 13.00 сәгатькә билгеләргә.
2. Гавами (ачык) тыңлауларда фикер алышына торган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 2021 елның 09 декабренә кадәр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Түбән Наратбаш авылы, Совет ур., 2Б йорт, Түбән Наратбаш авыл җирлеге Башкарма комитеты, телефон +7(84374) 4-22-46.
3. Әлеге карар Түбән Наратбаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерелергә тиеш:
- ТР, Буа районы, Түбән Нарабаш авылы, Совет урамы, 2А йорт;
- ТР, Буа районы, Бикмураз авылы, Комуна урамы, 43А йорт;
- ТР, Буа районы, Зур Кырлаңгы авылы, Кооператив урамы, 8А йорт.
4. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп тотуны үземә йөклим.

Татарстан Республикасы Буа муниципаль
районы Татар Буасы авыл
җирлеге башлыгы И.И. Галиуллин

Приложение к постановлению главы
Нижненаратбашского сельского поселения
Буинского муниципального района РТ
от « 15 » ноября 2021 г. № 5

Муниципаль берәмлекләр чикләренең
үзгәрешләр исәпкә алынган карта-схемасы




Шартлы билгеләр

- Татарстан Республикасы чиге
- Буа муниципаль районы чиге
- Муниципаль берәмлекләр чикләре
- А-Б - Түбән Наратбаш авыл жирлеге һәм «Буа шәһәре» муниципаль берәмлегенең чиктәш чиге
- В-Г - Ырынгы авыл жирлеге һәм «Буа шәһәре» муниципаль берәмлегенең чиктәш чиге
- Г-Д - Татар Буасы авыл жирлеге һәм «Буа шәһәре» муниципаль берәмлегенең чиктәш чиге
- Жирлекләренең административ үзәкләре
- Торак пунктлар

- Буа муниципаль районының Түбән Наратбаш авыл жирлеге территориясе составына керүче Буа муниципаль районының «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе
- Буа муниципаль районының «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе составына керүче Буа муниципаль районының Ырынгы авыл жирлеге территориясе
- Буа муниципаль районының «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе составына керүче Буа муниципаль районының Татар Буасы авыл жирлеге территориясе
- Буа муниципаль районының «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе составына керүче Буа муниципаль районының Түбән Наратбаш авыл жирлеге территориясе